ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№_1753__ «_30_»____12______2016 ел

2017 елга Мамадыш муниципаль
районының сәнгать-эстетик юнәлештәге
мәгариф оешмаларында балаларга
өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт
күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 14 декабрендәге «Татарстан Республикасының сәнгать-эстетик юнәлешле балаларга өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» 854 номерлы карары һәм Мамадыш муниципаль районы Уставы нигезендә Татартстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. 2017 елга түбәндәгеләрне расларга:

Мамадыш муниципаль районының нәфис-эстетик юнәлештәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә кушымта итеп бирелә торган норматив чыгымнар (1 нче кушымта);

2.Сәнгать-эстетик юнәлештәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарга 0,5 күләмендә төзәтмә коэффициенты.

3.Мамадыш муниципаль районы Финанс-бюджет палатасының балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнар нигезендә финанслауны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2017 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны муниципаль район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.П. Смирновага йөкләргә.

Җитәкче И.Э.Фәттахов

муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесенең
«30» ___12__ 2016 № 1753
карарына 1 нче кушымта

## Мамадыш муниципаль районының нәфис-эстетик юнәлештәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнар

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Территориаль дислокация | Норматив чыгымнар (1 балага сум) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | өч еллык уку срогы | дүрт еллык уку срогы | биш еллык уку срогы | җиде еллык уку срогы | иртә һөнәри ориентация |
| Музыка сәнгате | Шәһәр җирлеге | | | 36 445 | 40 176 | 58 473 |
| Музыка сәнгате | Авыл җирлеге | | | 40 815 | 44 972 | 65 325 |
| Рәсем сәнгате | Шәһәр җирлеге | | 21 530 | | 17 753 | 45 566 |
| Рәсем сәнгате | Авыл җирлеге | | 23 957 | | 19 788 | 50 778 |
| Хореография сәнгате | Шәһәр җирлеге | | | 41 080 | 33 340 | 131 757 |
| Хореография сәнгате | Авыл җирлеге | | | 46 098 | 37 414 | 147 805 |
| Гомуми эстетик сәнгать | Шәһәр җирлеге | | | 17 312 | | |
| Гомуми эстетик сәнгать | Авыл җирлеге | | | 19 394 | | |
| Фольклор сәнгате | Шәһәр җирлеге | | | 37 283 | 34 713 | 61 871 |
| Фольклор сәнгате | Авыл җирлеге | | | 41 869 | 38 994 | 69 409 |
| Эстрада-джаз сәнгате | Шәһәр җирлеге | 60 705 | | 53 996 | | 95 596 |
| Эстрада-джаз сәнгате | Авыл җирлеге | 68 000 | | 60 518 | | 107 040 |
| Театр сәнгате | Шәһәр җирлеге | 31 677 | | 27 623 | 26 752 | 45 124 |
| Театр сәнгате | Авыл җирлеге | 35 414 | | 30 898 | 29 926 | 50 270 |